Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Җикәнле Күл авылы

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«24» октябрь, 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Җикәнле Күл авылы гражданнар җыены

## КАРАР БИРДЕ:

1. 2025 елда яшәү урыны буенча Иске Дөреш авыл җирлеге Җикәнле Күл авылы территориясендә теркәлгән һәр бәлигъ булган кешегә 2000 (ике мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 1000 (бер мең) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- **торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Зиканни күл авылының М.Җәлил урамындагы юлны ремонтлау өчен вак таш сатып алу).**

2. РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү, контракт буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, Иске Дөреш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә.
3. Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Җикәнле Күл авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.
4. Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Җикәнле Күл авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Дөреш авыл җирлеге Башлыгы Р.М. Дусадбеков

Совет СТАРОДРЮШСКОГО сельского поселения